РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

с. Тюлячи

КАРАР

«2» октября 2024ел

№ 121

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 26 апрелендәге 88 номерлы «Опека, попечительлек (шул исәптән башлангыч опека, попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү, үз бурычларын үтәүдән опекун (попечитель) булудан азат итү буенча (суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затларга карата) дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 ноябрендәге 927 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 16 мартындагы 316 номерлы карары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 26 апрелендәге 88 номерлы «Опека, попечительлек (шул исәптән башлангыч опека, попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү, үз бурычларын үтәүдән опекун (попечитель) булудан азат итү буенча (суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затларга карата) дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) күрсәтелгән карар белән расланган Опека, попечительлек (шул исәптән башлангыч опека, попечительлек) билгеләү һәм опекун (попечитель) билгеләү, үз бурычларын үтәүдән опекун (попечитель) булудан азат итү буенча (суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган балигъ булган затларга карата) дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына:

А) 2.4 пунктында:

- беренче абзацта «гаризаны һәм документларны теркәгән көннән алып 15 календарь көннән артмаган вакытта» сүзләрен «документлар тапшырылган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

- алтынчы абзацта «Регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгән көннән алып 15 эш көне» сүзләрен «документлар тапшырылган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

Б) 3.5.2 пунктның 4 абзацында «3 көн дәвамында» сүзләрен «2 эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

В) 3.5.3 пунктның 3 абзацында «җиде көн дәвамында» сүзләрен «6 эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

Г) 3.5.4 пунктның 4 абзацында «өч көн дәвамында» сүзләрен «2 эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин